# Роль общения в жизни школьника

## Ата- аналар җыелышы

## «Укучы тормышында аралашуның роле»



«Бала күргәнен эшләр»

“Бала чакта кергән гадәт гомергә калыр”

“Баланы кыйнап юатма, көйләп юат”

“Баланы эшкә өйрәт,
эшен бетерергә дә өйрәт”

Татар халык мәкале.

# Гаиләдә бала тәрбияләүнең 6 принцибы

- Баланы кабул итү
- Баланы шәхес буларак тану
- Ата- ана мәхәббәте
- Бала өчен терәк булу
- Җаваплылык тәрбияләү
- Ата- ана авторитеты

# Ата- аналар белән әңгәмә

- «Бала белән аралашу» төшенчәсен ничек аңлыйсыз?
- Бер үк вакытта ярату һәм ягымлылык күрсәтеп, баланы җәзаларга мөмкинме?
- Сездә балада җаваплылык һәм үздисциплина тәрбияләүнең серләре бармы?
- Бала тәрбияләүдә сезнең өчен нәрсә мөһимрәк: баланы яратумы, ата- ана бурычын үтәүме?

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Мин балама үземнең балачагым турында еш сөйлим. | Әйе | Юк |
| 2 | Без балалар белән бик сирәк уйныйбыз. | Әйе | Юк |
| 3 | Минем балам миңа яңалыкларын һәрвакыт, ә кайвакыт серләрен дә сөйли. | Әйе | Юк |
| 4 | Әгәр минем баламның проблемалары була икән, ул мине һичшиксез ярдәмгә чакырачак. | Әйе | Юк |
| 5 | Баланың кечкенә генә хатасын да игътибарсыз калдырырга ярамый, бу балада оешканлык тәрбияләргә ярдәм итә. | Әйе | Юк |
| 6 | Без гаилә белән аена кимендә ике тапкыр ял итәргә барабыз. | Әйе | Юк |
| 7 | Әгәр балалар өй эшләрен эшләгәндә ярдәм сораса, мин һичшиксез булышам. | Әйе | Юк |
| 8 | Минем баламның бүген нинди китап укыганын мин төгәл беләм. | Әйе | Юк |
| 9 | Әгәр балам «2», «3» билгесе ала икән, аны җәза көтә. | Әйе | Юк |
| 10 | Баламны мактарга мин һәрвакыт сәбәп табам. | Әйе | Юк |
| 11 | Без чын күңелдән сөйләшергә яратабыз. | Әйе | Юк |
| 12 | Кайвакыт миңа балаларны тиргәү өчен генә вакыт сарыф иткән кебек тоела. | Әйе | Юк |
| 13 | Мин баламның башыннан еш сыйпыйм һәм кочам | Әйе | Юк |
| 17 | Мин балалар белән кырыс тонда сөйләшәм | Әйе | Юк |
| 15 | Балалар белән өй эшләрен әзерләшмәсәм, алар бөтенләй эшләмәячәк. | Әйе | Юк |
| 16 | Мин баламның хыялын беләм. | Әйе | Юк |
| 17 | Башка балаларны яки үземне балама үрнәк итеп сөйлим. | Әйе | Юк |
| 18 | Әгәр бала ачуыннан әйбер бозса, аны җәза көтә. | Әйе | Юк |
| 19 | Без балам белән китап һәм фильмнар турында сөйләшәбез | Әйе | Юк |
| 20 | Гаиләдәге проблемалар турында балалар белән сөйләшәбез. | Әйе | Юк |
| 21 | Әгәр мин авырсам яки арысам, балам минем хәлемә керә һәм булыша. | Әйе | Юк |
| 22 | Минем балам минем белән ешрак бергә вакыт үткәрергә теләвен белдерү. | Әйе | Юк |
| 23 | Балам белән аралашу миңа рәхәт. | Әйе | Юк |

# Уңай (позитив) игътибар

**0 дән 5 кә кадәр балл:**

Мөгаен сезнең балагызга уңай игътибар җитмидер. Сез эштә дә, өйдә дә буш түгел, ә балагызның аралашасы килә.Истә тотыгыз, игътибарның саны түгел, сыйфаты әһәмиятле. Теләсә нинди эш вакытында да балаларның мәктәптәге проблемалары, үзегезнең балачагыгыз турында сөйләшеп була.

**5 тән 10 га кадәр балл:**

Мөгаен сезнең балагызга игътибар җитмидер. Уйлап карагыз әле, бәлки сезнең аралашу формаль характердадыр: ашату, эчертү, көндәлеген карау? Ләкин бу гына аз.

**10 нан 15 кә кадәр балл:**

Мөгаен сезнең балагызга игътибар җитә. Сез үзара ышанычлы аралашу формалаштыргансыз. Балагыз сезнең белән киңәшләшеп яши.

# Җитәрлек дәрәҗәдә булмаган игътибар.

**1 дән 4 кә кадәр балл:**

Сезнең балагызга игътибар җитә. Бәлки кирәгеннән дә артыграктыр. Аның ирееген кысмыйсызмы? Бәлки аның проблемаларын да чишәсездер? Бу очракта баланың социаль үсеше тоткарлана, ул үз- үзенә ышанмаучан булып үсә.

**5 тән 9 га кадәр балл:**

Балага аралашу җитми. Аның сорауларына игътибарлырак булыгыз. Тормыш- көнкүрештә аннан да ярдәм сорагыз, фикере белән кызыксыныгыз.

**9 дан 13 кә кадәр балл:**

Бала белән аралашу бик түбән дәрәҗәдә. Балагызны мактарга да, башыннан сыйпарга да һәр буш минутыгызны файдаланыгыз, юкса, аның белән уртак тел табу авыр булачак.

# Кире (негатив) игътибар

**0 дән 2 гә кадәр балл:**

Сезнең гаиләдә барсы да яхшы: балагызга игътибар җитәрлек.

**2 дән 4 гә кадәр балл:**

Сезнең позиция артык кырыс түгелме? Әллә аз аралашасызмы? Ул үенә җәлеп итү өчен кирәкмәгән эшләр дә эшләп ташлый. Юк- барга тиргәмәгез.

**4 тән 8 гә кадәр балл:**

Сезнең балагыз ачулануларга шултиклем күнеккән, башкача аралашу бары турында оныткан. Үзенә игътибар җәлеп итү өчен ул сезне чыгырдан чыгара. Үз- үзегезнең бала белән аралашу алымнарын үзгәртегез.

Аны мактагыз. Башыннан сыйпагыз. Сөйләшкәндә гел өйрәтмәгез. Бала күзгә күренеп үзгәрер.

# Уйлагыз

- Җыелыш сезнең өчен файдалы булдымы?
- Бала тәрбияләү- ата- ананың изге бурычы булуы турында ышаныч тудымы?